ЯКШӘМБЕ
21 ГЫЙНВАР
1940 ел
№ 17 (5817)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

В. И. ЛЕНИН (1920 нче ел)

ЯШӘСЕН ЛЕНИНИЗМ!

Моннан ун алты ел элек, 1924 нче елның 21 нче гыйнварында кешелек дөньясының бөек даһие, бөтен дөнья хезмәт ияләренең сөекле юлбашчысы, остазы, атасы, иң якын дусты Владимир Ильич Ленинның ялкынлы йөрәге тибүдән туктады. Данлыклы гүзәл тормыш өзелде. Бу хәбәрне бөтен дөньяның эшчеләр сыйнфы, крестьяннәре, барлык хезмәт ияләре, прогрессив кешелек дөньясы тирән кайгы белән каршы алдылар.

Пролетар революциясенең бөек стратегы, данлыклы большевиклар партиясен төзүче һәм аның юлбашчысы, тарихта беренче тапкыр төзелгән социалистик дәүләтнең җитәкчесе, даһи фикер иясе, бөек революционер Владимир Ильич Ленинның исме кешелек дөньясы тарихының яңа эпохасы—җир шарының алтыдан бер өлешендә Бөек Социалистик Революциянең җиңүе белән турыдан-туры бәйләнгән.

ЛЕНИН! Бу бөек исем капитал коллыгында изелүче барлык эшчеләрнең, крестьяннәрнең, колония халыкларының көрәш һәм җиңү байрагы.

ЛЕНИН! Бу бөек исем 183 миллионлы совет халкының чиксез зур уңышларының бөек символы, бәхете, шатлыгы. Ленин исме һәрбер эшченең, һәрбер крестьяннең, һәр бер хезмәт иясенең йөрәгендә яши.

Бөек остазыбыз Ленин, совет халкына, бөтен дөнья эшчеләр сыйнфына, барлык хезмәт ияләренә һәм прогрессив кешелек дөньясына җиңүләр программасын, коммунизмның мәңге җиңелмәслек идеяләрен—марксизм-ленинизм тагълиматын калдырды. Бу тагълимат коммунизмның бөтен дөнья күләмендә тулысынча җиңүе өчен гаять зур корал булып тора.

Бөек остазыбыз Ленин—безгә дөньяда иң алдынгы, иң революцион, иң көчле, көрәштә чыныккан, тимердәй нык дисциплиналы, яңа типтагы бөек партияне—коммунистлар партиясен калдырды. Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә эшчеләр сыйнфы һәм крестьяннәр җир шарының алтыдан бер өлешендә капиталистларны, алпавытларны һәм барлык паразитларны юк итеп, бәхетле яңа тормыш—социализм төзеделәр.

Моннан ун алты ел элек, Ленин үлгәннән соң, аның гробы янында иптәш Сталин: партия члены дигән бөек исемне югары тотарга һәм саф итеп сакларга; партиябезнең бердәмлеген күз алмасы кебек сакларга; пролетариат диктатурасын сакларга һәм ныгытырга; эшчеләр һәм крестьяннәр союзын бөтен көч белән ныгытырга, Социалистик Республикалар Союзын ныгытырга һәм киңәйтергә; Кызыл Армияне һәм Кызыл Флотыбызны ныгытырга; бөтен дөнья хезмәт ияләренең союзы—Коммунистик интернационалны ныгытырга һәм киңәйтергә! ант иткән иде. Даһи Ленинның бөек көрәштәше, турылыклы шәкерте, аның эшен эзлекле рәвештә дәвам иттерүче иптәш Сталин белән берлектә, партиябез, Ватаныбызның барлык хезмәт ияләре бөек Ленинның васыятьләрен намус белән үтәргә ант иткәннәр иде. Юлбашчының бөек тарихи анты зур күтәренкелек һәм намус белән үтәлде.

Сталинчыл тарихи бишьеллыклар нәтиҗәсендә илебез танымаслык булып үзгәрде. Техник-экономик яктан элек артта калган, ярлы, культура ягыннан иң түбән торган илдән, аграр илдән, Ватаныбыз бөек индустриаль илгә, иң катлаулы барлык машиналарны үзендә җитештерүче илгә, оборона куәте ягыннан иң көчле илгә—Бөек державага әйләнде. Социалистик революциянең иң кыен бурычы хәл ителде—авыл хуҗалыгын коллективлаштыру төгәлләнде, колхоз строе тәмам җиңде. Советлар Союзында барлык эксплуататор сыйныфлар бетерелделәр, кешенең кешене эксплуатацияләвен һәм җәмгыятьнең сыйныфларга бүленүен тудыра торган сәбәпләр тулысынча юк ителделәр. Безнең илебездә коммунистик җәмгыятьнең беренче фазасы—социализм нигездә тормышка ашырылды.

Чиксез зур уңышларны күреп Ватаныбызның һәрбер намуслы гражданы чын күңелдән соклана, шатлана һәм горурлана. „Иптәш Сталин кызганып болай ди: Эх, Ленинның хәзер исән булмавы ничек кызганыч! Ул авыр заманда яшәде һәм авыр заманда эшләде. Безнең хәзер нинди юл үткәнебезне, нәрсәләргә ирешкәнебезне күрсен иде ул. Ильич канәгать булыр иде". (Микоян).

Тарихи яктан кыска гына срок эчендә илебезнең гаять зур уңышларга, тиңдәше булмаган җиңүләргә ирешүе өчен, бәхетле, шатлыклы, культуралы тормышыбыз өчен без, барыннан да элек, данлыклы большевиклар партиясенә—Ленин—Сталин партиясенә, юлбашчыбыз Сталинга, аның теоретик һәм оештыручылык даһилыгына бурычлыбыз.

Ленин марксизмны баеткан кебек, заманыбызның бөек теоретигы иптәш Сталин да марксизм-ленинизм теориясен үстерү, баету буенча гаять зур иҗади эш алып бара. Бер илдә социализмның җиңүе мәсьәләсе, социалистик дәүләт, пролетариат диктатурасы, илне социалистик индустриялләштерү, авыл хуҗалыгын коллективлаштыру, халык интеллигенциясе турындагы һәм башка бик күп теоретик мәсьәләләр иптәш Сталин тарафыннан иҗад ителделәр, баетылдылар, үстерелделәр.

Социализм иленең тарихи зур җиңүләре, искиткеч уңышлары кискен көрәш шартларында яулап алындылар. Халык дошманнарының, коммунизм дошманнарының мәкерле эшләрен илебезнең хезмәт ияләре партиябез, иптәш Сталин җитәкчелегендә бер-бер артлы фаш иттеләр, дошманнарның җылан ояларын тамыры белән йолкып ташладылар.

Бөек Ленинның гүзәл эше үсә, киңәя, көннән-көн яңа җиңүләр китерә. Без үзебезнең җиңүебезгә, коммунизмның тәмам җиңеп чыгуына ышанабыз. Чөнки безгә партиябез—Ленин—Сталин партиясе, марксизм-ленинизм теориясе белән коралланган партия җитәкчелек итә. Чөнки безнең эшебезгә, даһи Ленинның бөек шәкерте Сталин юлбашчылык итә.

Яшәсен Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның җиңелмәслек бөек байрагы!

Яшәсен Ленинизм!

СССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫНЫҢ УКАЗЫ

Капитан Н. Г. Саранчевка Советлар Союзы Герое дигән исемне бирү турында

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәгәне өчен һәм бу эштә күрсәткән батырлыгы һәм геройлыгы өчен

капитан Николай Георгиевич **Саранчевка,**

Ленин ордены һәм **„Алтын йолдыз"** медале тапшыру белән, **Советлар Союзы Герое** дигән исемне бирергә.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
19 гыйнвар, 1940 ел.

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ НАЧАЛЬНИКЛАР СОСТАВЫН СССР НЫҢ ОРДЕННАРЫ ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ

Фин ак гвардиячелегенә каршы көрәш фронтында командованиенең хәрби заданиеләрен үрнәк рәвештә үтәгән өчен һәм бу эштә каһарманлык һәм батырлык күрсәткән өчен, СССР Верховный Советы Президиумының указы белән, Кызыл Армиянең начальниклар составыннан зур группа СССР ның орденнары һәм медальләре белән бүләкләнде.

Өлкән лейтенант Семен Васильевич Бальбухов, полковник Александр Михайлович Кравцов, өлкән политрук Павел Прокофьевич Мирошниченко, өлкән лейтенант Григорий Титович Проценко һәм капитан Михаил Иванович Скитев **Ленин ордены** белән бүләкләнделәр.

„Кызыл байрак" ордены белән бүләкләнгән 76 иптәш арасында Советлар Союзы Герое полковник Григорий Пантелеевич Кравченко, кече командир Василий Георгиевич Аллилуев, полковой комиссар Иван Семенович Беляков, лейтенант Юрий Михайлович Голубовкский, капитан Владимир Авраамович Завилович, майор Тихон Васильевич Леденев һәм башкалар бар.

„Кызыл йолдыз" ордены белән 23 иптәш бүләкләнде.

„Батырлык өчен" медале белән 53 кеше һәм **„Сугышчан хезмәтләр күрсәткән өчен"** медале белән 6 кеше бүләкләнде. (ТАСС).

РСФСР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ПРЕЗИДИУМЫ УКАЗЫ

РСФСР ның почетлы исемнәрен—атказанган мәктәп укытучысы һәм атказанган врач исемен билгеләү турында

1. Элек билгеләнгән почетлы исемнәргә:

РСФСР ның атказанган фән һәм техника эшлеклесе,

РСФСР ның атказанган фән эшлеклесе,

РСФСР ның халык артисты,

РСФСР ның атказанган сәнгать эшлеклесе,

РСФСР ның атказанган артисты дигән исемнәргә өстәмә итеп

Халык мәгарифе һәм сәламәтлек саклау өлкәсендә күренекле хезмәтләре өчен түбәндәге почетлы исемнәрне билгеләргә:

РСФСР ның атказанган мәктәп укытучысы,

РСФСР ның атказанган врачы.

2. „РСФСР ның почетлы исемнәре турындагы положение"не һәм РСФСР Верховный Советы Президиумының РСФСР ның почетлы исемнәрен алган кешеләргә бирелә торган почет грамоталарының үрнәкләрен расларга.

РСФСР Верховный Советы Президиумы председателе А. БАДАЕВ.
РСФСР Верховный Советы Президиумы секретаре Г. КОЗЛОВ.

Москва, 11 гыйнвар, 1940 ел.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

19 нчы гыйнварда барлык юнәлешләрдә разведчикларның эзләнүләре, ә кайбер районнарда вак частьләрнең бәрелешләре булды. Петрозаводск юнәлешендә Китель районында безнең разведка группасы дошманның батальонын юкка чыгарды. Дошман батальоны 26 пулемет калдырды. Карелия бугазында—алгы частьләрнең бәрелеше булды һәм дошман зур югалтулар бирде.

Күп кенә районнарда безнең авиация разведка очышлары үткәрде һәм хәрби объектларда сугыш хәрәкәтләре алып барды.

Хезмәт җитештерүчәнлегенең 5 еллык планын 4 елда үтик!

Хезмәт җитештерүчәнлеген тагын да үстерү өчен

Серго исемендәге завод коллективы Москвадагы инструменталь заводы коллективының чакыруын зур күтәренкелек белән каршылады.

Начальнигы иптәш Скороходов булган цех коллективы беренче кварталда хезмәт җитештерүчәнлеген 25 процент күтәрү, беренче квартал программасын 25 нче мартка үтәү, беренче квартал ахырына ике участкының стахановча эшләвенә ирешү, продукциянең сыйфатын күтәрү турында йөкләмә алды.

Иптәш Кузьмин начальник булган цех коллективы да күп станокта эшләүчеләр һәм берничә профессияне үзләштерүчеләр санын ике тапкыр арттырырга, хезмәт җитештерүчәнлеген 25 процент күтәрергә, электроэнергиягә 50 процент экономия ясарга булды.

Хәзер бу цехлардагы сменалар һәм участкылар арасында социалистик ярыш киң колач ала. Аерым участкылар норманы 115—130 процент үти башладылар.

Заводның күп станокта эшләүче стахановчысы иптәш Маслов үзенең йөкләмәсендә болай дип яза:

„Мин ике фрезер станогында эшләп, еллык планны срогыннан алда—Октябрьнең 23 еллыгына үтәргә, хезмәт җитештерүчәнлеген 50 процент күтәрергә йөкләмә алам".

Заводның күп станокларда эшләүче башка эшчеләре дә шундый ук йөкләмә алдылар.

Йөкләмәләр үтәлә

Москвадагы инструменталь заводы коллективының чакыруына кушылып, „Спартак" комбинаты коллективы хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү буенча Сталинчыл өченче бишьеллык планын дүрт елда үтәү өчен конкрет йөкләмәләр алган иде.

Бу йөкләмәне уңышлы үтәү өчен комбинатның завод һәм цехларында социалистик ярыш киң колач ала. Күп кенә цехлар, бригадалар һәм сменалар планны арттырып үти башладылар.

Полувал заводының барлык бригадалары да гыйнвар аеның 10 көнлек планын арттырып үтәделәр. Прокатчы Исламгәрәев, дуплаучы Максимов, Арсентьев, Кутлин иптәшләр норманы 140—175 процент үтиләр.

Комбинатның парусин аяк киемнәре цехы да яхшы эшли башлады. Цехның мастеры иптәш Митрофанова сменасы планны арттырып үти. Бу сменада эшләүчеләрдән Сафронова, Крапивина, Шакирова, Хасанова һәм башка иптәшләр 10 көнлек норманы 135—170 процент итеп үтәделәр.

Ж. Сәфәргалиева.

* * *

Сталинчыл өченче бишьеллык исемендәге социалистик ярыш нәтиҗәсендә, 1 нче номерлы мех фабрикасы үткән ел планны срогыннан элек үтәде. Гыйнвар аеның 10 көнлек планы фабрикада 105 процент үтәлде. Чимал цехы 10 көнлек планны 125, шул ук цехның коры барабан бүлегендә план 196 процент итеп үтәлде. Отделкачылардан Гаврилова һәм Закирова иптәшләрнең бригадалары планны 158—166 процент үтиләр. Аерым стахановчылардан Латыйпова, Җәләлетдинов, Егоров һәм Минкин иптәшләр норманы һәр вакыт 160—180 процент итеп үти башладылар.

Фабрика коллективы гыйнвар ае планын срогыннан алда үтәү өчен көрәшә.

Р. Фазылов.

Нормаларын арттырып үтиләр

Гармон фабрикасы коллективы Москвадагы инструменталь заводы коллективының чакыруына кушылып эшләү нәтиҗәсендә зур уңышларга ирешә башлады.

Фабриканың агач материаллары эшләү цехы гыйнвар аеның 10 көнлек планын 9 нчы числода 100 процент итеп үтәде һәм пландан тыш 45 пар гармон корпусы эшләп чыгарды. Бу цехтагы Нефедов, Матвеев һәм Давыдов иптәшләрнең бригадалары хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрүдә аеруча үрнәк күрсәтәләр. Алар көнлек планны бер ярым, хәтта ике тапкыр арттырып үтиләр. Стахановчы Баһаветдинов, Забалуев, Нефедов иптәшләр 10 көнлек планны 150—190 процент итеп үтәделәр.

Фабриканың механика цехы стахановчылары да инструментальщикларның чакыруына хезмәт җитештерүчәнлеген күтәрү белән җавап бирәләр. Слесарь Зайцева, Кузнецова, Гыйззәтуллин һәм Пудовкин иптәшләр 10 көнлек планны 154—227 процентка кадәр житкереп үтәделәр. Механика цехы коллективы беренче квартал планын 140 процент итеп үтәү һәм бары тик югары сыйфатлы детальләр эшләп чыгару йөкләмәсен алып, фабриканың планкы цехы коллективын ярышка чакырды.

Фабриканың җыю цехы бригадиры иптәш Зиннурова үзенең эше турында болай ди:

— Москвадагы инструменталь заводы коллективының мөрәҗәгате безнең алга гаять зур җаваплы бурычлар куйды. Шул уңай белән безнең бригадада социалистик ярыш һәм стахановчылык хәрәкәте тагын да көчәя. Ярыш договорларын барыбыз да яңартып төзедек. Без 34 пар урнына уртача 45 пар гармон корпусы җиткерәбез. Фәйзерахманова, Асеева, Загускина, Липатникова иптәшләр аеруча яхшы эш нәтиҗәләре бирәләр. Алар планны 120—135 процент итеп үтиләр. Алдынгыларның эш тәҗрибәләрен башкаларга күчерү нәтиҗәсендә, яшь өйрәнчекләрдән Гатауллина, Лаврентьева, Павлова, Шибалова иптәшләр көнлек нормаларын 105—150 процентка кадәр җиткереп үти башладылар. Без гыйнвар ае планын арттырып үтәү өчен көрәшәбез. *Рәхматуллина.*

Яхшы башлангыч

Вахитов исемендәге жиркомбинатның баш конторасында шулай ук завод һәм цех контораларында эшләүче работниклар „хезмәткәрләрнең эш сәгатьләреннән тулысынча файдаланулары һәм штатларны кыскарту" турында „Правда" газетасының 6 нчы гыйнвар номерында урнаштырылган мәкалә белән бик нык кызыксындылар.

Шушы уңай белән комбинат хезмәткәрләренең гомуми җыелышы булды. Җыелышка катнашучы иптәшләр бу мәсьәләнең бик вакытлы күтәрелүен әйттеләр һәм мәкаләдә күрсәтелгән фактларның жиркомбинатта да зур урын алып торуын күрсәттеләр.

Жиркомбинатта штатларны кыскарту мәсьәләсе практик рәвештә тормышка үткәрелә дә башлады. Мәсәлән, комбинатның баш конторасында штат буенча 28 кеше эшләргә тиеш иде. Хәзер анда 14 кеше эшли һәм, шуңа карамастан, конторада эш күп штат белән эшләгәнгә караганда яхшырак бара.

Хәзер конторада югары квалификацияле работниклар гына эшлиләр. Алар эш сәгатьләреннән тулысынча файдаланып, үз эшләрен үрнәк булырлык итеп башкаралар һәм бер үк вакытта икенче бер тармаклардагы эшне үзләштерәләр. Мәсәлән, бухгалтерлардан Галиева һәм Михайлова иптәшләр расчет өстәлендә элек 3 кеше башкара торган эшне хәзер икәү башкаралар. Торпова һәм Зиновьева иптәшләр авансларга алган акчаларга отчет ясау өстәлендә шулай ук элек өч кеше башкарган эштә икәү эшлиләр. Җиһазларны хисапка алу буенча элек ике кеше башкарган эшне хәзер иптәш Суханов бер үзе башкара. Хәзер бу иптәшләрнең хезмәт хаклары 20 процентка үсте.

Берничә төрле профессияне берләштерү мөмкинлеге комбинатта бик зур. Комбинатның заводларында һәм бүлекләрендә смена табельщиклары бар. Ләкин аларның эш сәгатьләренең күпчелеге бөтенләй эшсез йөреп үтә. Смена мастерлары бу табельщикларның эшләрен бик җиңел башкара алачаклар.

Г. Тажиева.

СТАЛИН ҖИТӘКЧЕЛЕГЕНДӘ ЛЕНИН ЮЛЫ БЕЛӘН*)

Ем. ЯРОСЛАВСКИЙ

1924 нче елның 21 нче гыйнварында, кич 6 сәгать 50 минутта, Москва янында, Горкида Владимир Ильич Ульянов — Ленин үлде. Ул гаят зур акыл хезмәтеннән, үзенең барлык көчләрен чиксез киеренке эшләтүдән башланган каты авырудан соң үлде. Шулай да аның үлүе көтелмәгәндә булды, чөнки соңгы атналар һәм көннәр эчендә Лениннең сәламәтлеге яхшыра башлаган иде, партия һәм барлык хезмәт ияләре Владимир Ильичнең яңадан эшкә керешә алачагына ышанганнар иде.

Лениннең үлүе турындагы хәбәр төнлә белән большевиклар партиясенең сугышчан штабына, аның Үзәк Комитетына килеп җитте. Үзәк Комитетның шушы 22 нче гыйнвар төнендәге утырышы кебек утырыш бер кайчан да булганы юк иде әле. Бу утырышта Үзәк Комитет членнары, зур кайгы эчендә булганнары хәлдә, Лениннән башка ничек эшләү турында, безнең барыбызга да Ленин калдырган эш өчен — большевиклар партиясе өчен, Советлар иле өчен, пролетар революция өчен һәр кемнең җаваплылыгы нинди зур булу турында уйладылар.

Лениннең үлүе турындагы хәбәр бөтен илгә таралды. Моннан соң Лениннең юклыгына, үзенең исме миллионнарча эшчеләрнең, бөтен дөнья хезмәт ияләренең мәхәббәте белән чолганып алынган кешенең, үзенең исме буржуазиянең йөрәкләрендә дәһшәт һәм курку тудырган кешенең юклыгына ышану хезмәт ияләренә кыен иде. Лениннең үлүе — ул, миллионарча эшчеләр һәм хезмәт ияләре өчен үзләрен патшадан, алпавытлардан һәм капиталистлардан азат итү өчен көрәшкә күтәргән, эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең мәңгелек дошманнарын җиңүне китергән сөекле юлбашчының үлеме иде.

Ленин—большевиклар партиясен, коммунистлар партиясен, эшчеләр сыйныфының бердән-бер партиясен тудыручы һәм төзүче. Бу партия утыз елларга сузылган ныклы көрәштән соң, илебездәге эшчеләрне һәм крестьяннәрне марксизм—ленинизм байрагы астында җиңүле рәвештә социализмга алып килде, бу партия шушы байрак астында безнең социалистик Ватаныбызның хезмәт ияләрен коммунизм җиңүләренә алып бара.

Ленин шушы миллионнарча массаның җитәкчесе, дөньяның барлык изүчеләренә каршы восстаниенең юлбашчысы, социализмның, коммунизмның остазы, барлык хезмәт ияләренең дусы һәм иптәше.

Ленин—дөньяда беренче социалистик Совет дәүләтен оештыручы.

Ленин барлык илләрдәге коммунистлар партияләрен бөтен дөнья күләмендәге бердәм коммунистик партиягә, Коммунистик Интернационалга берләштерүче Коммунистик Интернационалга нигез салучы.

Бөтен дөньяның һәм Россиянең империалистик буржуазиясе Ленинне чиктән тыш дошман күрде. Октябрь революциясенә кадәр ул Ленинне төрмәләрдә утыртты, эмиграциягә куды, аның исмен яла ягу белән чолгап алды; 1917 нче елның июль көннәреннән соң буржуазия Ленинне Керенскийның ерткыч офицерлары һәм төрмә башлыклары судына бирергә тырышты. Контрреволюциянең этләре һәм агентлары Бөек социалистик революция җиңгәннән соң Ленингә каршы террорлык актлары хәзерләделәр һәм 1918 нче елны аны авыр яраладылар. Бөтен дөнья буржуазиясе ак гвардия восстаниеләренең уты һәм кылычы белән, интервенция боҗрасы белән, ачлык һәм авырулар белән пролетар революцияне буарга, эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең дошманнарына каршы канлы көрәштә революциянең Ленин—Сталин партиясе тарафыннан ирешелгән казанышларын юкка чыгарырга маташты.

Ленин безгә бөтен дөньяда бөек әһәмияте булган мирасны, үз таглиматын—марксизм - ленинизмны калдырды. Ул безгә коммунизм эшен ахрына кадәр, коммунизм бөтен дөньяда тулысынча җиңгәнчегә кадәр алып барып җиткерергә васият итте. Ленин тарафыннан тудырылганнардан иң бөеге,—ул, большевиклар партиясе. Лениннең бу партиясе хәзер тагын да зурырак бөек көч булып үсте. Ул Ленин комсомолының 9 миллионлы армиясен тәрбияләп үстерде.

Партия һәм комсомол күп миллионлы отряд булып, Ленин эшенең тулысынча җиңүенә, коммунизмның тулысынча җиңүенә Ленинчеләр армиясе сыйфатында алга атлыйлар. Социализм юлына баскан унар миллионнарча партиясез эшчеләр, колхозчылар һәм совет интеллигенциясе алар артыннан баралар. Бу армияне җиңә алырлык көч юк. Бу армияне Үзәк Комитет—Ленин һәм Сталин җитәкчелегендә көрәштә чыныккан большевиклар партиясенең Үзәк Комитеты,—Советлар иленең сугышчан штабы, пролетар революциянең сугышчан штабы алып бара. Үзәк Комитетның башында партиябезнең һәм бөтен совет халкының юлбашчысы, бөтен дөнья хезмәт ияләренең юлбашчысы, партиябезгә нигез салуның беренче көннәреннән бирле Лениннең иң якын көрәштәше Иосиф Виссарионович Сталин тора.

Империалистик һәм гражданнар сугышлары тарафыннан җимерелгән хуҗалыкны илебез Ленин партиясе җитәкчелегендә аякка бастырды. Ул Ленин исән вакытта уйланылган һәм эшләнгән планны—Советлар илен электрлаштыру планын тормышка ашырды. Уннарча зур электр станцияләре: Днепрогэс, Шатура, Волховстрой, Свирьстрой һәм башкалар—машиналарга, двигательләргә хәрәкәт, көч, шәһәрләргә һәм авылларга яктылык һәм елылык бирәләр. Ленин партиясе җитәкчелегендә бөтен халык хуҗалыгын социалистик үзгәртеп кору үткәрелде. Бөтенләй диярлек хәерче булган, алдынгы капиталистик илләрдән уннарча еллар артта калган илне революция һәм социалистик үзгәртеп кору куәтле державага, социализм иленә, алдынгы техника һәм культура иленә әйләндерелделәр. СССР күп кенә яклардан алдынгы капиталистик илләрне куып җитте һәм узып китте.

Әле күптән түгел генә СССР металл, чуен, корыч эшкәртү буенча, күмер чыгару буенча, машиналар җитештерү буенча бөтенләй диярлек соңгы урында иде, ә хәзер СССР чуен һәм корыч чыгару һәм кою буенча, нефть чыгару буенча, тракторлар һәм паровозлар җитештерү буенча алдынгы урыннардан берсендә тора.

Беренче бишьеллык башланганчыга кадәр—1928 нче елга кадәр—илебез башлыча авыл хуҗалыгы иле (аграр ил) иде. Сталинчыл ике бишьеллыклар елларында СССР куәтле индустриаль держава булып әверелде. СССР халык хуҗалыгының бөтен продукциясенең биштән дүрт өлешен промышленность продукциясе тәшкил итә. СССР промышленносты сугышка кадәрге белән чагыштырганда тугыз тапкырдан күбрәк үсте.

Авыл хуҗалыгы да бөтенләй башка булып әверелде. Эшчеләр сыйнфы һәм аның большевистик партиясе җитәкчелегендә эксплуататорларның соңгы сыйнфын—кулакларны тар-мар итеп, — Ленин—Сталин партиясе тарафыннан җитәкчелек ителә торган миллионнарча ярлылар һәм урта хәлле крестьяннәр таза тормышлы колхоз юлына нык бастылар.

Промышленность, авыл хуҗалыгы, транспорт һәм Кызыл Армия яңа техника, яңа машиналар һәм станоклар, яңа хәрби техника кораллары алдылар. Партия уннарча һәм йөзләрчә меңнәр кадрлар тәрбияләде, алар алдынгы техниканы үзләштерделәр. Промышленность, транспорт, авыл хуҗалыгы алдынгыларының куәтле стахановчылык хәрәкәте югары җитештерүчәнлекнең, югары хезмәт нормаларының дөньяда күренмәгән үрнәкләрен күрсәтте.

Сталинчыл бишьеллыкны тормышка ашыру Советлар илен көчле, куәтле һәм җиңелмәслек итте.

Советлар иленең бу куәтле үсеше, большевиклар партиясенең бу зур җиңүе нәрсә белән тәэмин ителделәр? Ленин партиясенең дөрес политикасы белән, хезмәт ияләре интересларына, ихтиаҗларына аның гаят зур игтибар бирүе белән; Ленин васиятләре юлыннан тайпылышсыз баруы белән, партиянең бөек постында, большевистик юлбашчының иң яхшы сыйфатларын үзендә берләштерүче, сыналган большевик,—иптәш Сталин торуы белән тәэмин ителделәр.

Троцкичылар, зиновьевчылар һәм капитализмның уң реставраторлары халыкара контрреволюциянең алдынгы отряды булып әверелделәр. Алар ленинизмның дошманнары, коммунизмның дошманнары буларак, партияне эчтән шартлату өчен кабәхәт рәвештә һәм ике йөзлелек күрсәтеп үзләрен партия сафларында саклап килделәр. Ленин эшенә хианәт итүче бу кабахәтләр халыкара империализмның турыдан-туры агентлары булып, чит ил разведкаларының „табышы“ булып әверелделәр. Ленин—Сталин партиясе аларны халык алдында фаш итте, юк итте, аларның җылан ояларын тамырлары белән йолкып ташлады.

Большевиклар партиясе һәм Совет хөкүмәте тайпылышсыз рәвештә тынычлык политикасы үткәрәләр, сугыш куркынычына каршы көрәшәләр. Совет халкы иленең куәтле оборонасын төзеде, көч тудырды, бу көчтән безнең дошманнарыбыз куркалар һәм аның белән хисаплашырга мәҗбүр булалар. Кызыл Армия, Кызыл флотыбыз, Кызыл Авиациябез барлык чикләрдә дә, дәһшәтле часовой кебек, Советлар илен саклыйлар. Бу армия 13 миллион украиналыларга һәм белорусларга Польша паннарының изүеннән азат ителергә ярдәм итте. СССР га каршы һөҗүм хәзерләгән палач Маннергейм җитәкчелегендәге халыкара бандитлар шайкасыннан азат ителүдә бу армия Финляндия хезмәт ияләренә ярдәм итә.

Марксизм - ленинизм таглиматы гаят зур көч булып әверелде. Аны Ленин һәм Сталин эшләделәр. Ул — эшчеләр сыйнфының сугышчан партиясен ничек оештыру, ныгыту һәм чыныктыру турындагы, аны революцион теория белән коралландыру турындагы таглимат; ул—эшчеләр сыйнфы белән крестьяннәр союзын ничек төзү, көрәшнең төрле шартларында бу союзны ничек саклап калу турындагы таглимат: ул— буржуазияне ничек бәреп төшерү, Совет дәүләтен ничек төзү, социализмны ничек төзү турындагы таглимат. Ленин—Сталин байрагы бөтен дөньяда Ленин юлыннан баручы эшчеләрнең һәм хезмәт ияләренең байрагы булып әверелде.

Ленин—Сталин таглиматы безгә эшебезне ахрына кадәр, коммунизмның тулысынча җиңүенә кадәр алып барып җиткерергә ярдәм итәр. Ленин—Сталин таглиматы бөтен дөнья халыкларына үз өсләреннән алпавытлар һәм капиталистлар властын алып ташлауга ярдәм итәр. Ленин—Сталин таглиматы безгә бөтен дөньяда хезмәт ияләренең бердәм союзын, бөтен дөнья Совет Социалистик Республикалар Союзын төзергә ярдәм итәр.

Һәм без барыбыз да: Лениннең яш һәм карт шәкертләре, эшчеләр, крестьяннәр, совет интеллигенциясе, барлык халыкларның, барлык милләтләрнең хезмәт ияләре—шуны телибез һәм ничек кенә булса да шуңа ирешербез. Һәр кем Лениннең таглиматын, аның тормышын яхшы белсә, һәр кем үзен Ленин кебек итеп тәрбияләсә, моңа шул кадәр тизрәк һәм уңышлырак ирешеп булачак.

Ленин 1924 нче елның 21 нче гыйнварында үлде. Большевикларның Ленин партиясе Үзәк Комитеты партиягә һәм барлык хезмәт ияләренә карата үзенең мөраҗәгатендә, Ленин партиябезнең һәрбер членының йөрәгендә яши, дип язды:

„Ленин һәрбер намуслы эшченең йөрәгендә яши“.

„Ленин һәрбер ярлы крестьяннең йөрәгендә яши“.

„Ленин миллионнарча колониаль колларның йөрәгендә яши“.

Бу барлык миллионнарча кешеләр: картлар, яш үсмерләр, мәктәп балалары—пионерлар—Владимир Ильич Ульянов-Лениннең ничек үсүен һәм тәрбияләнүен, аның ничек укуын, эшчеләр эше өчен, коммунизмның җиңүе өчен аның ничек итеп революцион көрәшче булып әверелүен, аның үзенең бөтен гомере буена бу көрәшне ничек алып баруын белергә телиләр һәм белергә тиешләр.

⁂

Без, җир шарының алтыдан биш өлешендә капиталистик дәүләтләр яшәвен, гадел булмаган, империалистик, басып алу сугышының учаклары яшәвен, Советлар Союзына каршы корал кайраучы империалистик дәүләтләр яшәвен онытмыйбыз. Лениннең бөек мирасына, Советлар иленә кул сузарга маташучыларның барсына да рәхимсез һәм җимергеч удар бирү өчен без һәр вакыт хәзер торырга тиешбез.

Иптәш Сталин, хәзергә капиталистик чолганыш яшәгәндә, эшчеләрнең һәм крестьяннәрнең социалистик дәүләтенең көчен һәм куәтен ныгытырга кирәк, Кызыл Армияне, Совет разведкасын ныгытырга кирәк, безнең бөтен халкыбызны мобилизация хәзерлегендә тотарга кирәк, дип өйрәтә.

Безнең тәҗрибәбезгә таянып, безнең уңышларыбызны күреп, эшчеләр һәм крестьяннәр бөтен дөньяда Совет властын төзәрләр. Ул чагында бөтен дөньяда Бөтен Дөнья Совет Социалистик Республикалар Союзы төзелер. Менә шул чагында бөтен дөньяда коммунизмның чыннан да чәчәк атуы, кешелек дөньясының барлык көчләренең чыннан да чәчәк атуы башланыр.

Узган йөзнең ахрыннан башлап Ленин белән берлектә большевистик партияне төзүче, бөтен юлны Ленин белән кулга-кул тотышып үтүче Сталин Лениннең бөек таглиматын баета һәм үстерә. Сталин безнең партиябезне, барлык большевикларны Ленин таглиматын ничек эшләргә һәм, аның белән кулланып, социализм өчен көрәшнең барлык мәсьәләләрен дөрес хәл итәргә өйрәтә.

Советлар иле иптәш Сталин җитәкчелегендә Ленин юлы белән коммунизмның тулысынча җиңүенә бара.

*) Кыскартылып алынды.

Ленин һәм Сталин ГОЭЛРО картасы янында. Художник Налбандян картинасы (ТАСС фото-клишесе).

УЛ КӨННӘРДӘ...

Иртән сәгать өч... Колонналы зал. Төн, илне басып тора торган гаят зур кайгы кебек авыр, караңгы.

Ленин юк.

Аң бу коточкыч фактны күтәрә алырлык көчле түгел. Ленин һәм үлем—ул башка сыя торган нәрсә түгел. Ленин үлмәскә тиеш. Ул, үзен тудырган халык кебек, мәңгелек. Ул дөньяда беренче социалистик революциянең бөек эшләрендә мәңгелек. Ул китәргә тиеш түгел, ул безнең белән. Ул һәрбер эшченең торагында, һәрбер крестьяннең өендә. Ул халыкара эшчеләр сыйнфының омтылыш мие һәм акылы.

Ләкин траур байраклары, газеталарның кара рамкалары, урамнардагы кайгылы күренешләр Лениннең физик үлүе турында сөйлиләр. Менә ул, туганыбыз, якыныбыз, сөекле Ильич мәңгегә күзләрен йомган килеш ята. Ильич хәзер торыр да, тизчән хәрәкәте белән үзенең эш кабинетына керер, һәм гадәттәге эш кайнар: телефон шалтыратыр, фронттан сводкалар таләп итәр, Ленинград эшчеләре өчен ашлык төягән эшелоннарның кайда тоткарлануларын сорар, галимнәргә пайоклар бирүне ашыктырыр, чираттагы контрреволюцион заговор турында Дзержинскийдан белешер кебек тоела. Ләкин Ильич хәрәкәтсез ята. Димәк, Ленин юк? Димәк, бу коточкыч дөрес? Димәк, Ильич аяк очында минем почетлы караулда торуым ул коточкыч төш түгел?

Истәлекләр күз алдына килеп бастылар. Париж... Эмиграция еллары. Авеню Орлеан 5 нең кечкенә генә эшчеләр рестораны... Җыелышта ликвидаторлар белән, троцкичылар белән, впередовчылар белән Ленин араны өзә, Ильичнең юк итүче аргументациясе ударлары астында Даннар, Либерлар, Богдановлар чыңлыйлар... Аннары империалистик сугыш, Карпатта Августовский урманнарында бөтен полклары һәм дивизияләре белән һәлак булучы рус солдатлары. Висла, Неман һәм Стрый елгалары канлы суларны китерәләр. Читлеккә япкан арыслан кебек, социал-демократиянең хианәтенә борчылган Ильич нәфрәт эчендә ыргыла. Бөек 1917 нче ел килә. Смольнида Советлар съезды, анда власть турындагы мәсьәлә хәл ителә. Съезд делегатлары тарафыннан зур күтәренкелек белән тәбрикләнүче Ильич трибунада.

Меньшевиклар-эсерлар контрреволюциясенең шашынулы кычкырышы.

„Узурпаторлар! Басып алучылар!“

Ильич елмая. Аның янында Сталин трубкасын тыныч кына тарта. Большевистик нык төтеннән эсерлар, меньшевиклар съездан чыгып качалар:

„Без җаваплылыкны өстебезгә алырга теләмибез...“.

Совет властаы өчен тавыш бирүче съезддан аларга җавап итеп күңелле, ныклы көлү яңгырый... Аннары гражданнар сугышы. Кызыл полклар Деникинны тар-мар итәләр. Ильич Смольнидагы кабинетында Украинага китүче работникларга наказлар бирә:

— Барыннан да элек җир турындагы декретны иглан итәргә кирәк. Элекке ялгышларны—авыл хуҗалыгы коммуналары төзүне ашыктыру кебек ялгышларны кабатламаска кирәк. Серпуховка Сталин янына барыгыз, ул эшне ничек алып барырга икәнлекне күрсәтер...“

Тагын Ленинград. Элекке Таврический сарайда Коминтернның II нче конгрессы ачыла. Делегатлар дулкынланалар. Бүген аларның бик күпләре Ленинне—исме бөтен дөнья буржуазиясенә дәһшәт тудыручы кешене, бөтен дөньяның миллионнарча хезмәт ияләре тарафыннан чиксез мәхәббәт, хөрмәт һәм ышаныч белән чолганып алынган кешене беренче тапкыр күрерләр һәм ишетерләр.

1922 нче елның көзендә Горкида булган соңгы очрашу. Ильич авырый. Ильичкә авыру бик авыр! Ул бер минутка гына да тынычлана алмый. Аның уе мотор кебек өзлексез эшли. Ул калган көчләрен җыеп, коммунистик хәрәкәтне Фроссарлардан һәм Хеглундлардан ничек чистарту турында киңәшләр бирә. Кулны кыса.

— Хушыгыз...

Истәлекләр яңгыр болыты кебек, өзеләләр.

Мәңгегә хуш, туганыбыз Владимир Ильич!

Почетлы караул сменасы алмашына. Кешеләр өзлексез агым булып үтеп торалар. Ильич яныннан көне-төне үтеп торалар. Ул алар бәхте өчен үзенең бөтен тормышын бирде, халыкның иленең барлык почмакларыннан килгән, 27 градуслы суыкта калтыранган уллары һәм кызлары үтәләр. Союзлар йорты колонналы залының сакчылары гаҗизләнде. Биш-ун минут үтми, залда тавыш күтәрелә. Ул Ильич гробы яныннан үтүче кем дә булса берәү авыр югалтудан һәм кайгыдан һушсыз булып егылучы була. Толып кигән крестьян карчыгы үтә, аның җыерчыклы битләреннән күз яшләре тәгәри. Иваново-Вознесенский тукучылары үтәләр, гаят зур мәхәббәт белән алар материегә Ленин портретларын чигеп эшләгәннәр, алар ул портретларны йөрәкләрендәге тирән кайгы белән күкрәкләрендә алып баралар.

Партия кайгыда, эшчеләр сыйнфы кайгыда. Халык кайгысының чиге юк. Халыкның кайгысын кем басар? Яңа җиңүләргә халыкны Ленин кебек кем рухландырыр? Алдагы җиңүләргә барлык кыенлыклар аркылы Ленин юлыннан аны кем алып барыр? Партия дә, эшчеләр сыйнфы да, халык та үзләрен Лениннең ышанычлы юлдашы булган кеше, аның турылыклы дусы, көрәш буенча какшамас туганы булган кеше, куәтле большевистик партиянең барлык иң яхшы хасиятләрен, сыйфатларын һәм үзенчәлекләрен үзендә гәүдәләндерүче кеше, үзенең бөтен гомере буенча Ленин белән бер фикерне уйлаган, Ленин белән бер эшне тудырган, Ленин белән бердәм рәвештә хезмәт ияләрен җиңүгә алып барган кеше алып барыр, дип хис итәләр.

⁂

Зур театр. Советлар Съездының Ленин истәлекләренә багышланган траурлы утырышы.

— Сүз иптәш Сталинга бирелә—ди акрын гына, ниндидер аеруча йөрәктән чыккан тавыш белән Калинин.

Партия Сталинның Ленинне һәр кемнән дә күбрәк яратканын белә. Аңа һәр кемнән дә авыррак. Югалтуның барлык нәтиҗәләре барыннан да элек аның өстенә төшәчәк. Ләкин Сталинның ирке тимердәй нык. Йөзендәге бер генә мускулы да калтыранмас. Тотнаклылык тавышы эчтәге борчылуны белдерми. Гади булмаган тынлык эчендә бөек Сталин антының металл кебек нык сүзләре яңгырый.

„Без, коммунистлар,—үзенә аерым калып кешеләре. Без махсус материалдан төзелгәнбез. Без—пролетариатның бөек стратегының армиясен, иптәш Ленин армиясен тәшкил итүчеләр. Бу армиядә тору дәрәҗәсенә ирешүдән дә югары һичбер нәрсә юк“.

Антның сүзләре куәтле чүкеч ударлары кебек яңгырыйлар. Күңелләрне дер селкетә торган сүзләр, шундый революцион пафос сүзләре, сүзләрнең иң зур художестволары да андый дәрәҗәгә кадәр күтәрелә алмаслар. Алар үзләренең политик зурлыклары белән, үзләренең тирән дөреслекләре белән, үзләренең кешеләрдәгечә гадилек белән кешеләрне чолгап алалар һәм рухландыралар. Бу антны делегатлар гына ишетеп калмады, аны ил ишетте, аны бөтен дөнья хезмәт ияләре ишетте. Алар Сталин сүзләре белән сөйләделәр. Аларның тирән мәгънәле фикерләрен, аларның үткенлекләрен, аларның Ленин эшенең җиңелмәслегенә ышануларын, аларның гаят зур югалту кайгысын кичерүче сугышчан омтылышын иптәш Сталин әйтеп бирде.

Еллар үттеләр, каты, данлыклы көннәр үттеләр. 1924 нче елның 26 нчы гыйнварында иптәш Сталин тарафыннан бирелгән ант үтәлде. Эчке дошманнар тар-мар ителделәр. Сталин антына—халык антына каршы пычрак кулларын күтәрүчеләргә, халыкны чагу өчен, социализм эшенә зарар китерү өчен халык култыгына үрмәләгән җылан төсендәге кешеләргә кайгы! Халык узып барышлый җыланны басып сытты, аны канауга типкәләп төшерде һәм ашыгыч рәвештә тагын да алга китте.

Совет җире өстендә бөек Сталин Конституциясе кояшы, җиңүче социализм Конституциясе кояшы балкыды. Бөек Ленин—Сталин партиясе үз сафларының чисталык байрагын югары тота. Эшчеләр сыйнфы белән крестьяннәрнең колхоз строе белән цементландырылган союзы кыя таш кебек җиңелмәслек булып әверелде. Советлар иле оборонасы сагында куәтле Кызыл Армия, Флот һәм Авиация тора, алар могҗизалар, героик эшләр күрсәтәләр. Капиталистик бүре көтүе явызлык белән тешләрен шакый. Ленин—Сталин тарафыннан пролетар интернационализм рухында тәрбияләнгән совет эшчеләр сыйнфы капиталистик илләрдәге пролетариат белән үзенең элемтәсен өзлексез ныгыта.

Ленин—Сталинның эшен бөтен дөньяда җиңүле рәвештә ахрына кадәр җиткерергә бөтен дөнья хезмәт ияләре яңа бөек ант бирәләр.

Д. Мануильский.

В. И. ЛЕНИН
Телинкөгә эшләнгән рәсем. Керамика. Казагстанның Алма-Ата шәһәрендәге Керамика станциясе мастерлары эшләгән.

ЗУР РӘХМӘТ

(Бурят халык җыры)

Паровоз коткарды үлемнән,
Егылган һәм талган атымны,
Большевик коткарды коллыктан
Буылган, тапталган халкымны.

Йөгереп, ашкынып паровоз
Килде дә, атыма булыша.
Күзләрен ачарга халыкның
Мәктәпләр ачылды олыста[1]).

Туктады сап-салкын янгырлар,—
Күлләрдә барлык кош шатлана.
Ульянов
Советлар властын төзеде,—
Бу безгә иң бөек тантана.

Гөл янып, балкып тор, гүзәл ут!
Рәхмәт—чакма ташка, мамыкка!
Рәхмәт, Ленин, чиксез зур
рәхмәт!—
Тормыш һәм көч бирдең
халыкка!

М. Садри тәрҗемәсе.

БӨТЕН ДӨНЬЯНЫ БАЛКЫТА ЛЕНИНИЗМ НУРЛАРЫ

(Татар халык җырларыннан)

Биек тауларның башында
Күренә чуен юллары,
Бөтен дөньяны балкыта
Ленинизм нурлары.

Иптәш Ленин, тыныч йокла,
Мавзолеең эчендә,
Көрәшергә әйткән сүзең
Һәммәбезнең исендә.

Иртә торып тышка чыксам,
Кошлар кунган тирәккә,
Иптәш Ленин үзе үлсә дә
Исме калды йөрәктә.

Исле чәчәк өзелсә дә
Исе аңкый болында.
Иптәш Ленин үзе үлсә дә,
Эше халык кулында.

Чылтырап аккан чишмәләрдән
Төшеп сулар алабыз,
Укып эшләргә өйрәткән
Безгә Ленин бабабыз.

Зур, зур шәһәрләр салына
Эшчеләр кулы белән,
Безне Сталин җитәкли
Ленинның юлы белән!

ТАУЛАР АРТЫННАН ТАҢ АТТЫ

(Эвенк халык җыры)

Таулар артыннан таң атты,
Төннәр кыскарды хәзер.
Әнә эвенк күтәрелде,
Эшкә барырга әзер.
Әнә карый бөтен якка,
Әнә тауларны күрә,
Әнә шул таулар артыннан
Аңа зур кояш көлә.
Бу кояшта—нурлары
Лениннән,—
Партиясе, шатлыгы илемнең!

М. Садри тәрҗемәсе.

Бәхилләшү

(Грузинчадан тәрҗемә)

Түбән йөри нигә кара болыт,
Алазанга*) бөркеп караңгылык?

Аяз көндә болыт кайдан чыккан?
Нәрсә булган, күк чыраен
сыткан?

Күк шуңарга елый—Ленин үлгән;
Бәхилләшә җир дә Ленин белән.

Без айрылдык сөйгән
атабыздан—
Таулар, сулар елый шул
кайгыдан.

Үлде безгә тормыш биргән кеше,
Карый алмас инде безнең эшне;
Ул советка инде килә алмас,
Безгә инде киңәш бирә алмас.
Тыныч йокла, Ленин, һич
борчылма,
Без барабыз җиңеп синең юлда!
Калды синең батыр балаларың,
Авыр җәза көтә дошманнарың!
Бер ялгызым Ахун тауларында
Мин, билгесез ерчы, утрам
шунда;
Мин нык тотып кулыма
мылтыгымны,
Күзәтәм: мин аңлыйм
бурычымны.
Нык булса да йөрәк, яшем тама
Ачы яштән күзем томалана.

Ә. Исхак тәрҗемәсе.

---
1) Авыл.
*) Алазан—Грузиядә елга.

ҺИЧ ВАКЫТТА ШИҢМӘС АЛ ГӨЛЛӘР

(Лезгин халык җыры)

Хәерчелек илтте караңгыга,
Кабер иде безгә дөньяда;
Алып чыкты Ленин яктылыкка,
Рәхмәт әйттек аңа җырларда.

Әй телеграф, синең чыбыкларың
Үткәрдек без ничә авылда,
Үлгәнлеген сөйләп юлбашчының
Җылатыргамени кайгыда.

Яшел урман тора, күрәмен мин,
Тәрәзәмнең минем каршында.
Москвада бар зур йорт, даһи
Ленин
Исән кебек яши ул шунда.

Ленин яткан пыяла йорт тора
Гөлбакчадан ерак бер җирдә.
Безгә ирек биргән юлбашчыбыз
Чәчәкләрнең ятсын эчендә.

Тигез безнең яңа юлларыбыз,
Бик нык безнең яңа күперләр.
Даһи Ленин йөргән бакчаларда
Һич вакытта шиңмәс ал гөлләр.

Князьләрнең ауды оялары,
Лезгиннәргә килде чын шатлык;
Бәхетле син, Совет Дагыстаны,
Ленин бирде безгә азатлык!

Ә. Исхак тәрҗемәсе.

ЧЕЧЕН ХАЛЫК ЖЫРЫ

Якты кояш балкый, нурлар сибә:
Нур бирүче Ленин, син бит ул!
Җылы җилләр томаннарны куа:
Алсу нурлы Ленин, син бит ул!

Ленин кояш кебек, күтәрелә,
Халыкларга бирә туры юл.
Һәр ярлыга килеп, әкрен генә:
„Ничек яшисен?“ дип, сорый ул.

Элек патша безне газаплады,
Актык малны талап ашады.
Ленин безгә җирләр, сулар
бирде,
Явызлыкны йолкып ташлады.

Эхмәт Ерикәй тәрҗемәсе.

Ленинге багышланган костер

Казанның пионерлар һәм Мәктәп Балалары Йорты Ленин, Сталин портретлары белән, лозунг һәм плакатлар белән матур итеп бизәлде. Бирелә бүген балаларның бөек даһи В. И. Ленинне искә алуга багышлап шәһәр костеры үткәреләчәк. Тамаша залында, костер яныңда, Ленин турында беседа һәм кино булачак.

В. И. ЛЕНИН КАЗАН УНИВЕРСИТЕТЫНДА

Бөтен дөнья хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы Владимир Ильич Ленинның тормышы хәзер аның исемендәге Казан Дәүләт Университетының революцион тарихы белән нык бәйләнгән. Патша самодержавиесенә каршы В. И. Ленинның революцион көрәше шунда башлана.

Владимир Ильичтә юридик һәм политик-экономик фәннәргә зур кызыксыну булу сәбәпле, ул 1887 нче елның август аенда, бик зур авырлыклар белән, Казан университетының юридик факультетына укырга керә. Бу, патша Россиясендә полиция терроры иң нык көчәйгән вакыт була. Патша Александр III гә һөҗүм ясалгач, студентлар өстеннән полиция надзоры тагын да көчәя. Кечкенә генә каршылык өчен дә бик күп студентлар университетлардан чыгарылалар һәм сөргенгә җибәреләләр.

Патша хөкүмәтенең бу реакцион политикасына Россиянең зур шәһәрләрендәге университет студентлары баш күтәрүләр һәм сходкалар оештыру белән җавап бирәләр. 1887 нче елның 16 нчы декабрендә Казан университетында студентларның сходкасы үткәрелә. Алдынгы студентлар сходканы үткәрү турында киңәшмәләр уздыралар һәм политик таләпләр белән петицияләр хәзерлиләр.

1887 нче елның 16 нчы декабрендә, иртән 11 сәгаттә, Казан университеты студентларының сходкасы башлана. Аның башлануына түбәндәге факт сәбәп була:

Политик яктан ышанычсыз булган студент Португалов университеттан чыгарыла һәм ул документларын сорап университет канцеляриясенә килә. Ләкин аңа документын кире кайтармыйлар. Чөнки ул документлар полиция идарәсенә җибәрелгән булалар.

Партугалов канцеляриядән чыгып, университет коридорыннан үткәндә:

— „Хәзер!“ —дип кычкыра.

Бу, сходканың башлануы турында сигнал була. Сходканы оештыручы студентлар аудитория ишекләрен ачып:

— „Барыгыз да сходкага!“— дип кычкырып йөриләр. Бу чакыруга студентларның күпчелеге кушыла. Нәтиҗәдә, сходка студентларның массовый баш күтәрүләренә әйләнә. Сходкага катнашучы студентлар университет ректоры алдына үзләренең политик петицияләрен куялар. Бу петицияләрдә алар сходканың башлануына төп сәбәп итеп түбәндәгеләрне күрсәтәләр:

„Башка бер нәрсә дә түгел, бәлки гомумән алганда Россиядәге тормыш һәм аерым алганда студентлар тормышы дучар ителгән барлык шартларның түзә алмаслыгын аңлау, шулай ук шушы шартларга җәмгыятнең игтибар бирүен теләү безне монда җыйды“.

Ленин бу сходканы актив оештыручы була һәм аңа турыдантуры җитәкчелек итә.

Студентлар сходкасын бастыру өчен шәһәр полиция идарәсе махсус батальон җибәрә. Студентларга каршы каты репрессия башлана. Сходканы оештыручы студентлардан 40 кеше кулга алына, алар арасында Владимир Ильич тә була. 4—5 нче декабрьдә(иске стиль белән) төнлә Владимир Ильичне кулга алалар. Владимир Ильич кулга алынгач, пристав аңа болай ди:

— Сез нәрсәгә котырынасыз, яш кеше, сезнең алда стена бит.

Владимир Ильич аңа:

— Әйе, стена, ләкин черек стена, төртсәң аварга тора,—дип җавап бирә.

Бу вакыйгалардан соң В. Ильичкә Казанда торырга рөхсәт ителми, полиция аны Кокушкино авылына сөргенгә җибәрә.

Кокушкино авылында торганда Владимир Ильичнең һәрбер адымын полиция күзәтеп тора.

Владимир Ильич университетта үтә торган фәннәрне бик зур тырышлык белән үзлегеннән өйрәнә һәм тирән үзләштерә. 1892 нче елны ул Петербург университетының барлык курслары буенча экстернат тәртибендә экзамен бирүгә рөхсәт ала, экзаменны яхшы итеп бирә һәм беренче степень диплом ала.

1888 нче елның көзендә Владимир Ильичкә Казанда торырга рөхсәт ителә. Ул, хәзер Ленин музее булган йортта 1889 нчы елның май аена кадәр тора. Бу вакыт эчендә ул Маркснын „Капитал“ын өйрәнә һәм Н. Е. Федосеев тарафыннан оештырылган марксистлар түгәрәгендә эшли башлый.

Д. Иртуганов.

БЕРЕНЧЕ САФЛАРДА БУЛЫРБЫЗ

1931 нче ел иде... Этнә районы, Түбән Бәрәзә авылының ярлы һәм урта хәлле крестьяннәре культуралы таза тормыш яулап алуда бердәнбер дөрес юлга—колхозлар юлына бастылар.

1932 нче елны, колхозчыларның бердәм таләпләре буенча, колхозыбызга бөтен дөнья пролетариатының юлбашчысы бөек Ленин исме бирелде. Колхозга Ленин исме бирелгәч, бу бөек исемне колхозчыларыбыз намус белән акларга, дисциплинаны ныгытырга, намус белән эшләргә, таркаулыкка каршы, кулак калдыкларына каршы рәхимсез көрәшергә вагдә иттеләр һәм алар үз вагдәләрен үтәделәр.

Кырларда кул белән эшләнә торган интектергеч хезмәтне, гектардан 5—6 центнер гына уңыш алуны колхозчыларыбыз онытты инде.

Җирләребез куәтле тракторлар белән эшләнә. Хәзер колхозыбызның 7 чәчү машинасы, 9 ургычы, 9 молотилкасы, 2 печән чабу машинасы һәм күп санда башка машиналары һәм кораллары бар. Колхозда хезмәт җиңеләйде. Иген уңышы нык күтәрелде. 1937 һәм 1938 нче елларда гектардан уртача 15,09 центнер уңыш алынды. 1939 нчы елны, климат шартлары беркадәр начар булуга да карамастан, гектардан 10 центнер бодай, 17 центнер арыш уңышы алдык. Ә иптәш Бакир Җәббаров җитәкчелегендәге алдынгы бригада гектардан 102 пот уңыш алды.

Авылның төсе танылмаслык булып үзгәрде. 400 кеше сыешлы клуб төзелде, ясле, тулы булмаган урта мәктәп, агролаборатория, уку өе, бала тудыру йорты, 2 су тегермәне, ял бакчасы төзелде. Картлар йорты салынды, анда 40 ка якын карт колхозчылар тәрбияләнәләр.

Татарстандагы иң алдынгы колхозлар белән берлектә, безнең колхоз узган ел Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнашты һәм беренче дәрәҗә диплом, җиңел автомашина һәм 10.000 сум акча белән бүләкләнде. 1940 нчы елны да күргәзмәдә катнашу хокукы алу өчен хәзер колхозчылар арасында социалистик ярыш киң җәелдерелде. Гектардан 100 пот уңыш алу лозунгысы астында көрәш алып барыла.

Безнең колхоз югары уңыш алу өчен көрәштә иң алдынгы урыннарның берсен алып, Ленин исмен намус белән аклар.

И. Сабитов.
Этнә районы, Ленин исемендәге колхоз председателе хезмәтен башкаручы.

В. И. ЛЕНИН
Төрекмәнстанның Ашхабад шәһәрендә эшләнгән палас.

ҖЫЛАДЫ МӘСКӘҮ — ТАШКАЛА

Архангель өлкәсе, Приморский районы, Нижняя Золотица авылының бәетчесе Марфа Семеновна Крюкова сүзләреннән язып алынды)

Мәскәү дигән безнең ташкалада
Килде безгә шунда зур кайгы.
Дулкынланды бөтен Мәскәү—елга,
Нак дингездәй ярсып чайкалды.
Нурын җуйды күктә якты кояш,
Баш иделәр агач - урманнар,
Анабыз — җир түкте ачы күз яш,
Кузгалдылар карлы бураннар.
Җылады бөтен Мәскәү—ташкала,
Ай болытка гүя капланды,
Зур хәсрәткә төште һәр кем шунда,
Бөтен халык шунда тын калды.
Тын калды да халык, уйга талды,
Кара кием бар да киенде,
Күңелсезлек җирне каплап алды,
Батыр башлар түбән иелде.
Бик күңелсез авыр хәбәр килде
Шул Горкидан безгә тагын да,
Кояшыбыз безнең гүя сүнде,
Нуры бетте гүя айның да,
Сүнде гүя якты йолдызыбыз
Авыр хәбәр безгә килгәндә —
Юлбашчыбыз безнең, Ильичебез,
Күз нурыбыз Ленин үлгәндә.
Ул кайда соң шулай китә бездән?
Кайгылы һәм ерак юлгамы?
Кай якларга, нинди юллар белән?
Көнбатышка, чит-ят илгәме?
Ул китәрме утырып пароходка,
Ул китәрме утырып карабка?
Безне ташлап әллә көнчыгышка
Ул китәрме ерак-еракка?
Юк китмәс ул инде көнчыгышка,
Калаларга, ерак-еракка,
Китмәс инде утырып пароходка,
Китмәс инде утырып карабка —
Күрер өчен тирән дингезләрдә
Бозваткычлар безнең йөргәнне,
Ак дингездә, бозлар арасында
Салкын кышка алар кергәнне.
Кечеләрдән алып зурларгача
Аңладылар барын, белделәр,
Киткәнлеген аның бик еракка,
Югалганын аның күрделәр,—
Китмәде ул биек тау артына,
Һәм артына Мәскәү — елганың,
Китмәде ул бездән арьягына
Караңгы һәм куе урманның,—
Ул мәңгегә китте арабыздан
Кадерле дус, бөек юлбашчы,
Күз нурыбыз Ильич китте бездән,
Бөек Ленин — илнең атасы.
Янына ук илтеп Кремльнең
Мавзолейгә аны куйдылар,
Тавыш тавышы тынды татлы теленең,
Якты күзләр йомылып калдылар.
Ак кулларын куеп күкрәгенә,
Яшел кием киеп ул ята,
Ул уянмас өч-дүрт көннән генә,
Алмас аны һич кем уята.
Уятырга инде булмас аны,
Туксәк тә без кайнар яшьләрне,
Уйнатсак та шаулы арфаларны,
Чертсәк тә алтын кылларны,
Ул ишетмәс безнең әндәшкәнне,
Ул ишетмәс безнең җырларны.
Шунда аны Кызыл Армиянең
Ышанычлы батыр уллары
Саклап тора көн-төн. Батырларның
Мылтык тоткан таза куллары.
Тора алар шунда уйга талып,
Уйга талып, тирән хәсрәттә,
Тора алар авыр сулыш алып,
Һәм борчылу саклап йөрәктә.
Тыныч йокла, Ильич, кадерлебез,
Борчылма син уйлап илеңне.
Ышанычлы безнең армиябез,
Таза һәм нык корыч шикелле.
Синең тормыш үтте борчылуда,
Күрә алмый шатлык-бәхетне,
Ул булмады тыныч бер вакыт та,
Күрде бары кайгы-хәсрәтне.
Кичердең син бик күп газапларны
Сабыр иттең ләкин аларга,
Яклаганга барлык халыкларны,
Ярлыларның дусты булганга,
Ябылдың син салкын төрмәләргә,
Куылдың син кара урманга.
Кечеләрдән алып зурларгача,
Барып данлы Кызыл Мәйданга,
Җир астына төшә торган юлга
Агылалар сине карарга.
Агылалар бар да карар өчен,
Күрер өчен сине кыю лачын,
Сине, безнең якты нурыбызны,
Сине, безнең сүнмәс йолдызны.
Исегез сез, шаулы җилләр, бердән,
Исегез сез, барлык дүрт яктан:
Исегез сез, җилләр, көнчыгыштан,
Исегез сез, җилләр, көньяктан,
Исегез сез, җилләр, көнбатыштан,
Исегез сез, җилләр, төньяктан.
Куптарыгыз табут тактасын сез,
Ачылсыннар якты күзләре,
Йокысыннан аны уятыгыз,
Ишетелсен татлы сүзләре.
Кадерлебез, Ильич, уян инде,
Күзеңне сал туган илеңә,
Ташкаланны кара, Москваны;
Кайтып, эшли торган җиреңә,
Килеп кер дә тагын үз бүлмәңә,
Син үзеңнең утыр урыныңа,
Яз ашыгыч язу ак кәгазгә,
Каләмеңне алып кулыңа,—
Язу җибәр бөтен Россиягә,
Таш Мәскәүгә—данлы калага,
Һәм данлыклы Ленин шәһәренә,
Колхозларга, фабрикаларга.
Кечеләрдән алып зурларгача,
Сез, кешеләр, өмет итмәгез,
Авылларга безнең, калаларга
Кайтмас инде Ильич, көтмәгез.
Ул дустына, бөек Сталинга
Бөтен эшне биреп калдырган,
Халыкларның бөек остазына
Ул шуларның барын тапшырган.
Ә Сталин уен Ильич белән,
Ильич белән бергә уйлый ул,
Уйлар уйлап һаман сөйли ул:
„Мәңге синнән, Ильич, аерылмабыз,
Аерылмабыз, бергә барырбыз,
Туры юлдан читкә тайпылмабыз.
Мәңге сине искә алырбыз“.

Ә. Исхак тәрҗемәсе.

Кокушкино авылында

Питрәч районы, Ленино (элекке Кокушкино) авылында Владимир Ильич Ленин музее-йорты. РӘСЕМДӘ: сулда— В. И. Ленин бүлмәсе, уңда — өстә: В. И. Ленин музееның тышкы күренеше һәм аста В. И. Ленинның караваты.

„Ленин 1887 нче елны Казан Университетына укырга керде, ләкин озак та үтмәде, студентларның революцион хәрәкәтендә катнашкан өчен кулга алынды һәм университеттан чыгарылды. Ленин Казанда Федосеев тарафыннан оештырылган марксизм түгәрәгенә керде“ (ВКП(б) тарихының кыскача курсы, бит 20).

Владимир Ильич Ленин университеттан куылгач, полиция күзәтүе астында Казаннан 40 километр ераклыктагы Кокушкино (хәзерге Ленино) авылына сөргенгә җибәрелә. Владимир Ильич бу авылда бер ел була, крестьяннәрнең тормышы белән якыннан таныша.

Кечкенә генә Кокушкино авылы бөек юлбашчының тормыш һәм көрәш тарихында зур урын алып тора.

Татарстан Совнаркомы, бөек юлбашчының истәлеген мәңгеләштерү теләге белән, Кокушкино авылында Ленин торган йортны элекке күренешенә китерергә һәм анда музей ачарга карар бирде. Бу карар нигезендә 1939 нчы елның 21 нче гыйнварында — Ленинның үлүенә 15 ел тулу көнендә музей ачылды.

Йортның тышкы һәм эчке күренеше Ленин торган вакыттагыга яраклаштырып, элекке хәленә китерелде. Менә В. И. Ленин бүлмәсе. Анда В. И. Ленинның караваты, китаплар шкафы, эш өстәле һәм берничә урындык. Эш өстәлендә Ленинның шул вакытта укыган китаплары: Маркснын „Капитал“ы, Пушкинның „Капитан кызы“ дигән әсәре, Лермонтов, Островский, Некрасов, Добролюбов әсәрләре, Дарвинның „Кешенең барлыкка килүе“ дигән әсәре һәм башкалар. Бу китаплар Ильичнең никадәр күп укыганлыгын, революцион көрәш юлын кече яштән үк тырышып өйрәнгәнлеген ачык күрсәтеп торалар.

Менә Анна Ильинична бүлмәсе. Ул да монда күзәтү астында яшәгән. Бу бүлмәдә шул чордагы документлар һәм портретлар урнаштырылганнар.

Музей эшли башлаганга бер генә ел әле. Шушы кыска гына вакыт эчендә музейдә 6300 кеше булды. Алар музейдәге документлар, портретлар һәм башкалар аркылы Ленинның көрәш юллары белән таныштылар. Музейне караучылар музей турында яхшы отзывлар калдыралар.

„Без, „Ленинский призыв“ колхозы колхозчылары һәм колхозчы хатын-кызлары, бөек Ленинның сөргендә яткан вакыты белән таныштык. Аның эшчеләр һәм крестьяннәр бәхете өчен армыйталмый эшләвен күрдек. Ленин образы безне җиңүгә рухландыра. Без колхозыбызда тагын да тырышыбрак эшләрбез, стахановчылар булырбыз. **Фазлиев, Сәйфиев, Сафин, Таҗеттинова, Сәләхова, Таҗиева, Гафиятова**“.

„Без, Питрәч районы пионерлары, Ленин музеендә булдык. Музейне карау безгә көч бирде. Без үсәрбез, чыныгырбыз, Ленин эше өчен турылыклы көрәшчеләр булырбыз. Пионер вожатые **Николаев**“.

„Музейне карау бездә гаять зур тәэсир калдырды. Без хезмәт ияләренең бөек юлбашчысы Ленинның портретлары һәм аның турындагы тарихи документлар белән таныштык. Ленин безгә шатлыклы һәм бәхетле тормыш бирде, Безгә культуралы итеп яшәргә, кадерлебез В. И. Ленинның үткәндәге тормыш һәм көрәш юллары белән танышырга мөмкинлек биргән Ленин—Сталин партиясенә, бөек юлбашчыбыз иптәш Сталинга рәхмәт. **Яланцов һәм Яланцова**“.

„Без, Питрәч районы „Марс“ колхозы янындагы комсомол оешмасы комсомолецлары бөек Ленинның безне капитал коллыгыннан азат итү өчен, эшчеләрне һәм крестьяннәрне якты һәм бәхетле тормышка чыгару өчен ничек көрәшкәнлеген аңладык. Без Ленин комсомолецлары бөек Ленин юлыннан барырбыз, коммунизмга бару юлында бөек Ленин эше өчен көрәшербез. Яшәсен коммунизм! 18 комсомолец исеменнән **Халимов**“.

Бу кыска, ләкин тирән мәгнәле отзывлар музейнең гаять зур политик әһәмияте турында сөйлиләр. Ул эшчеләрне, крестьяннәрне һәм интеллигенцияне коммунизм рухында тәрбияләүгә, Ленин—Сталин партиясе тарихын тирәнтен өйрәнүгә ярдәм итә. Шуңа күрә дә аны тагын да баетырга һәм киңәйтергә кирәк.

Музейне баету һәм киңәйтү буенча быел тагын күп кенә чаралар үткәрелә. Йорт тирәсендәге бакчаны яшелләндерү, йорт алдына полисадник ясау, таш юлны музейгә кадәр җиткерү өчен хәзерлек эшләре алып барыла. Владимир Ильич эштән соң ял итеп, су коенып, балык тотып йөргән Ушна суында су коену урны ясалачак. В. И. Ленин туган көнгә—22 нче апрельгә хәзерлек уңае белән, бакчада Ленинга һәйкәл куелачак.

Экскурсантлар өчен дә уңайлы шартлар тудырылачак. Алар өчен махсус йорт салына. Анда буфет, ашханә, уку залы, ятак бүлмәсе һәм башкалар булачак. Казаннан һәм колхозлардан килүче экскурсантларны йөртү өчен махсус автомашина булдырыла.

Ленинның үлүенә 16 ел тулуга хәзерлек уңае белән музей тарафыннан колхозда кызыл почмак оештырылды, аңа аерым көтепханә бирелде.

Музей территориясен тәртипкә китерүдә „День Красной Армии“, „Яңа көч“, „Колос“, „Марс“, „Беренче Май“, Мулланур Вахитов, Ворошилов һәм Ленин исемендәге колхозлар зур булышлык күрсәттеләр.

Шәйнурова.
Музей директоры.

Чит илләрдә

ЕВРОПА СУГЫШЫ

БЕРЛИН, 19 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросы Германия армиясенең верховный командованиесе тарафыннан чыгарылган түбәндәге сводканы тапшыра: „Көнбатышта аеруча вакыйгаләр булмады. 18 нче гыйнварда кич белән дошманның аерым самолетлары төньяк-көнбатыш Германия өстендә очтылар. Бу очышлар вактында Англия самолетлары берничә тапкыр Голландия территориясен боздылар“.

ПАРИЖ, 19 гыйнвар. (ТАСС). Сугыш хәрәкәтләре турында кичә кич Парижда игълан ителгән рәсми белдерүдә „Вогезы районында Франциянең алгы постларыннан берсе дошман отрядының атакасын кире кайтарды, берничә плен алды“ дип хәбәр ителә.

Бүген иртә белән чыгарылган белдерүдә фронтта „әһәмиятле бер нәрсә дә булмады“ дип хәбәр ителә.

ЛОНДОН, 19 гыйнвар. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 17 нче гыйнварда Англиянең көнбатыш ярлары буенда, 5.494 тонна авырлыгындагы „Кэрнросс“ пароходы минага бәрелеп, баткан. Пароходның 48 кешелек командасы Англиянең көньяк-көнбатыш ярларындагы пунктларның берсенә чыккан.

Норвегиянең 1.140 тонна авырлыгындагы „Энид“ пароходына Шотландиянең төньяк-көнчыгыш ярлы буенда су асты көймәсе тарафыннан торпеда җибәрелгән. Пароходның командасы коткарылган.

ЯПОНИЯ АМЕРИКАНЫҢ ДАГВАЛАРЫН КИРЕ КАКТЫ

НЬЮ-ЙОРК, 19 гыйнвар. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Вашингтон хәбәрчесе тарафыннан бирелгән хәбәргә караганда, Кытайда америкалылар тарафыннан күрелгән зарарларның түләнергә тиешлеге турында Американың күп кенә дагвәләрен Япония кире каккан. Япония сугыш хәрәкәтләре вактында күрелгән зарар өчен, халыкара хокук нигезендә, Япониянең җавап бирмәскә тиешлеген күрсәтә. Американың кайбер рәсми кешеләре, — Япония Кытайга сугыш игълан итмәгәнгә күрә, зарарларны түләргә тиеш, дип саныйлар. Ләкин, юристларның фикеренчә, хәтта сугыш игълан ителмәгән хәлдә дә Япония җаваплы түгел. Японнар,—1854 нче елда Америка сугыш карабының Никарагуада Грейтаун шәһәрен җимергәнлеген һәм Франция милекчелегенә зур зарар китергәнлеген, ләкин Америка Кушма Штатларының зарарларны түләүдән баш тартканлыкларын, күрсәтәләр. Америка Кушма Штатлары 1914 нче елда Вера Крус портын (Мексика) басып алганнан соң да шундый ук позициядә торганнар.



Горкида В. И. Ленин үлгән йорт. Новецкий фотосы (ТАСС фото-клишесе).

ЛЕЙБОРИСТЛАР ОЕШМАЛАРЫНЫҢ АК ФИННӘРГӘ ЯРДӘМГӘ КАРШЫ ЧЫГЫШЛАРЫ

ЛОНДОН, 19 гыйнвар. (ТАСС). Ньюкастльдә лейбористларның Үзәк район оешмасының секретаре Уотерс лейбористлар оешмасыннан чыкты һәм үзенең коммунистлар партиясенә керергә теләгәнлеген белдерде. Уотерс лейбористлар партиясендә 20 ел торды. Ул чыкканнан соң урындагы җитәкчеләр,—Уотерс үзенең чыгышларында Советлар Союзының тышкы политикасын яклаганлыктан, ул лейбористлар партиясе өчен яраклы түгел иде, — дип белдерделәр.

Ньюкастльдә лейбористларның үзәк район оешмасының махсус рәвештә чакырылган җыелышында Уотерс, Советлар Союзының ак финнәргә карата политикасын яхшы дип тапканлыгын, ә лейбористлар партиясе лидерларының хәрәкәтләрен хиянәтчел хәрәкәтләр дип санаганлыгын тагын бер тапкыр белдерде. Җыелышта сөйләүчеләр Уотерсны якладылар. Кабул ителгән резолюциядә җыелыш бер тавыштан Уотерска ышаныч белдерде.

Апминистерда (Эссекс графлыгы) лейбористлар оешмасы, ак финнәргә корал җибәрүгә каршылык күрсәтүне һәм азатлык өчен көрәштә Финляндия эшчеләренә ярдәм күрсәтү өчен эшчеләр сыйныфының барлык оешмаларын берләштерү эшенә булышлык күрсәтүне лейбористлар партиясенең башкарма комитетыннан таләп итеп, резолюция кабул итте.

Литографлар, граверлар һәм типография эшчеләре союзының Лондон бүлеге дә шундый ук резолюция кабул итте.

АНГЛИЯ ХӨКҮМӘТЕНЕҢ ЯҢА ЧАРАЛАРЫ

ЛОНДОН, 19 гыйнвар. (ТАСС). Англия матбугаты, шушы елның язына Англиянең сугыш тырышлыкларын шактый активлаштыруга карата хәрби кабинетның план төзегәнлеген хәбәр итә. Англия хөкүмәте судноләр төзелешен һәм сугыш материаллары житештерүне шактый киңәйтергә уйлый.

„Ньюс кроникл“ газетасының хәбәр итүенә караганда, якындагы берничә атна эчендә Англиянең бөтен сәүдә флоты коралландырылачак.

„Ньюс кроникл“ның язуына караганда, күп кенә товарларны читтән кертү эшендә яңа чикләүләр билгеләнә. Тагын күп кенә куллану әйберләренә карточка системасы кертелсә кирәк.

АК ФИННӘР АРМИЯСЕНДӘ РИЗАСЫЗЛЫК

СТОКҺОЛЬМ, 19 гыйнвар. (ТАСС). „Норшенс Флагман“ газетасы редакция сотрудникының Маннергейм солдатлары белән беседасын игълан итә. Ак финнәр армиясендәге настроениеләр турында солдатлардан берсенең түбәндәгечә сөйләве буенча хөкем итәргә кирәк. Солдат Х. газета сотрудникына түбәндәгечә белдергән: „Безнең арада җанлылык хөкем сөрә дип әйтүләр дөрес түгел. Безнең барыбызны да бирегә көчләп куып китерделәр һәм Кызыл Армиягә каршы сугышырга мәҗбүр итәләр. Фронтта безнең тормыш турында бик күп сөйләргә мөмкин булыр иде, ләкин исемнәрне күрсәтеп тулысынча сөйләү солдатлар арасында бары тик массовый атуларга гына китерәчәк“.

Солдат Х. үзенең сөйләвен дәвам иттереп, түбәндәгечә белдерә: „Безнең часть алгы позицияләрдә инде һичбер ялсыз-нисез ике атнадан бирле тора. Азык начар, кыр кухняләре фронттан ерак урнашканнар“.

Аннан соң солдат газета хәбәрчесенә солдатлар арасында хөкем сөрә торган массовый ризасызлык турында һәм күп частьләрдә чуалышлар турында сөйләгән.

АНГЛИЯНЕҢ АМЕРИКАДАГЫ ИЛЧЕЛЕГЕНЕҢ БЕЛДЕРҮЕ

ВАШИНГТОН, 19 гыйнвар. (ТАСС). Англиянең Америка Кушма Штатларындагы илчелеге, Германия экспорты белән көрәш турындагы указны үткәрү эшендә Америка Кушма Штатлары өчен ташламалар ясауны таләп итүгә карата Американың сорауларын карарга экономик сугыш министрлегенең хәзер торганлыгын игълан итте. Сораулар 1 нче февральдән дә соңга калмыйча кертелергә тиеш.

ГОЛЛАНДИЯ ЯРЛАРЫ БУЕНДА МИНАЛАР ШАРТЛАВЫ

БЕРЛИН, 19 гыйнвар. (ТАСС). Германия информация бюросы Амстердамнан, кичә Голландиянең Гельдер дигән хәрби порты тирәсендә мина шартлаганлыкны хәбәр итә. Шартлау аркасында килгән зарар чама белән 7 мең гульден исәпләнә. Күп кенә йортлар зарарланган. Бу районда декабрь аенда ук миналар шартлавы булган иде. Бу юлы да сүз Англия миналары турында бара дип уйлыйлар.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Кытай чыганакларыннан алынган хәбәрләргә караганда, 18 нче гыйнварда кытай гаскәрләренең төп көчләре Кантоннан төньяк-көнчыгышка һәм төньяк-көнбатышка таба 20—35 километрда булганнар. Кытай гаскәрләре Кантонны өч яктан чолгап алырга хәзерләнәләр.

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендә кытай гаскәрләре көньяктан, төньяктан һәм көнчыгыштан Наньнинга һөҗүмне дәвам иттерәләр. Стратегия ягыннан әһәмиятле булган һәм Гуньлиньгуань дигән тау аралыгы (Наньниннан төньяк-көнчыгышта) кытай гаскәрләре тарафыннан алынды. 18 нче гыйнварда Цэтан шәһәре дә (Наньниннан төньяк-көнчыгышка таба 20 километрда) шулай ук кытайлар тарафыннан алынды.

Үзәк Кытайда

Шанхай—Нанкин—Ханчжоу өчпочмагында партизаннар хәрәкәте көчәя. Цзясин (Шанхай—Ханчжоу тимер юлында әһәмиятле шәһәр) тирәсендә барлык стратегик пунктларны партизаннар контроль астында тоталар. 13 нче гыйнварда Цзянсиннан көньякка таба берничә километрда кытай партизаннары тимер юл полотносын сүтеп, японнарның гаскәри поездларын һәлакәткә очраттылар. Цзясин—Сучжоу тимер юл тармагында (Цзясиннан төньякта) партизаннар шул ук көнне японнарның тагын бер гаскәри поездларын һәлакәткә очраттылар. Һәлакәтләр нәтиҗәсендә японнарның зур югалтулары булды.

15, 16 һәм 17 нче гыйнварда партизаннар японнарның Тунсяндәге һәм Цзясиннан көньяк-көнбатышка таба башка пунктлардагы гарнизоннарына берничә тапкыр атака ясадылар. Атакалар вактында японнарның 400 гә якын солдаты үтерелде. Партизаннарның югалтулары бик аз.

Уси, Сучжоу һәм башка күп кенә районнарда партизаннар белән япон гаскәрләре арасында көн саен диярлек бәрлешләр булып тора. Соңгы көннәрдә курчак-властьларның вәкилләре белән хисаплашу вакыйгаләре берничә тапкыр булды. Партизаннарның кечкенә бер отряды Усигә үтеп керде. Бу отряд анда японнар тарафыннан билгеләнгән өяз начальнигын үтерде. „Синьшуньбао“ газетасы тарафыннан бирелгән мәгълүматларга караганда, җиңел пулеметлар белән коралланган партизаннар 14 нче гыйнварда Чжанпу шәһәренә (Шанхай—Нанкин тимер юлында) бәреп кергәннәр һәм урындагы курчак властьларның күренекле ике вәкилен пленгә алганнар.

Төньяк Кытайда

„Шуньбао“ газетасының хәбәр итүенә караганда, 16 нчы гыйнварда Бэйпин—Ханькоу тимер юлында, Юаньши станциясе тирәсендә (Хэбэй провинциясе) японнарның гаскәри поезды һәлакәткә очрады. Һәлакәт тимер юл полотносы астына партизаннар тарафыннан куелган минаның шартлавы аркасында булды. Японнарның 200 гә якын солдаты үтерелде һәм күп санда корал һәм амуниция юкка чыгарылды.

МАРКСИЗМ-ЛЕНИНИЗМНЫҢ КЛАССИК ӘСӘРЕ

(И. Сталин. „Марксизм һәм милли колониаль мәсьәлә“. Татгосиздат, 1939 нчы ел).

Шушы көннәрдә генә Татгосиздат тарафыннан иптәш Сталинның „Марксизм һәм милли колониаль мәсьәлә“ исемле китабы татар телендә басып чыгарылды.

Сайланма мәкаләләр һәм речьләр җыентыгы исме астында чыккан бу китапка иптәш Сталинның милли-колониаль мәсьәлә буенча язган әсәрләре, сөйләгән речьләре кергән.

Милли мәсьәлә марксизм-ленинизм теориясендә иң мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора. Шуның өчен дә Маркс, Энгельс, Ленин һәм Сталин үзләренең бөек хезмәтләрендә бу мәсьәләгә гаять зур урынны бирделәр. Чөнки марксизм-ленинизм милли мәсьәләгә, миллионлаган хезмәт ияләрен капитализм изүеннән коткару һәм пролетариат диктатурасын яулап алу өчен империализмга каршы көрәш эше белән бергә бәйләнгән эш дип карый.

Иптәш Сталинның „Марксизм һәм милли колониаль мәсьәлә“ исемле китабы аның „Марксизм һәм милли мәсьәлә“ дигән әсәре белән башлана. Бу хезмәт иптәш Сталин тарафыннан 1912 нче ел азагында һәм 1913 нче елның башларында языла. Милли мәсьәләдә большевистик программаның теоретик нигезләрен эшләүдә һәм милли мәсьәләдә марксизмга бөтенләй дошман караштә булган меньшевикларга, бундчыларга һ. б. барлык оппортунистларга каршы көрәштә иптәш Сталинның бу хезмәте бөек Октябрь революциясенә кадәр үк гаять зур урын тотып килде. Иптәш Сталинның бу әсәре большевистик партиянең милли мәсьәлә буенча алдагы бөтен эш һәм көрәш программасы булды.

Бу әсәрдән тыш, китапка: „Милли мәсьәлә буенча доклад“ (РСДРП ның VII Бөтен Россия (апрель) конференциясендә 1917 нче ел, 29 нчы апрельдә ясалган доклад), „Октябрь перевороты һәм милли мәсьәлә“, „Россиядә милли мәсьәлә буенча Совет властының политикасы“, „Милли мәсьәләдә партиянең чираттагы бурычлары“ (РКП(б) ның X съездына тезислар), „Октябрь революциясе һәм рус коммунистларының милли политикасы“, „Совет республикаларын берләштерү турында“ һәм башка бик күп әсәрләр кергән. Кыскасы, марксизм-ленинизмның классик әсәре булган бу китапка иптәш Сталинның милли мәсьәләгә карата булган бөек әсәрләре кертелгән. Китапның азагында „кушымталар“ дигән аерым бер бүлек бирелгән һәм анда партиянең милли мәсьәлә буенча карарларыннан иң әһәмиятлеләре бирелгән.

Иптәш Сталинның гүзәл хезмәтләрен эченә алган бу китапны татар хезмәт ияләре зур шатлык белән каршы алдылар.

Х. Ярми.

ВУЗЛАРДА КАНИКУЛЛАР АЛДЫННАН

Казанның В. И. Ленин исемендәге Дәүләт университетының студентлары үзләренең кышкы каникулларын күңелле итеп үткәрәчәкләр. Отличник студентлардан 50 кеше кызыл башкалага—Москвага экскурсиягә бара, 30 физкультурник үзләренең ялларын туристларның Зөядәге лагерында үткәрәчәкләр. 85 кеше төрле ял йортларына җибәрелә.

Каникул вактында Казанда калучы студентларның ял вакытларын файдалы, дөрес һәм күңелле итеп үткәрү буенча махсус план төзелде. Бу планда студентларның кино-театрларга, циркка культура походларын үткәрү, музейләргә экскурсияләрен оештыру күздә тотыла.

Каникул чорында Казанга Саратов университетының хоккейчылар командасы киләчәк һәм Казан университетының командасы белән очрашачак. Волейбол буенча блиц-турнир үткәреләчәк. 24 нче гыйнварда Обсерваториягә чаңгыларда 100 кешелек поход үткәрелә. Шулай ук шашка-шахмат турнирлары, ату ярышлары һәм үзешчәнлек сәнгате кичәләре дә үткәреләчәк.

Яңа клуб төзелде

Саба районының „Яңа Тормыш“ колхозы колхозчылар көче белән яңа клуб төзеде. Аны төзү 25 мең сумга төште. Клуб матур итеп җиһазландырылды. Ул февраль башларында ачылып эшли башлаячак.

С. Кәримов.

БЕЛДЕРҮ

23 нче гыйнвар, кич 5 сәгатьтә Укытучылар йортында (Островский урамы, 10 нчы йорт) Казан шәһәренең укытучылар һәм комсомол активының киңәшмәсе була. Көн тәртибендә: „ВЛКСМ Үзәк Комитетының X нчы пленумы йомгаклары“. Докладчы—ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты секретаре иптәш Шәмсиева.

Җаваплы редактор
Һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

ШӘҺӘРНЕ ЧИСТА ТОТУ ҺӘМ КАРДАН ТАЗАРТУ ТУРЫНДА
Казан Шәһәре Башкарма Комитетының
МӘҖБҮРИ КАРАРЫ
1940 нчы ел, 16 нчы гыйнвар

Урамнарны, тротуарларны, мәйданнарны, ишек алларын чиста тоту һәм аларны кардан тазарту турында Казан Шәһәре Советы Президиумының 1939 нчы ел, 11 нче гыйнварда чыгарган 2 нче номерлы мәҗбүри карарын үзгәртеп, Казан Шәһәре Башкарма Комитеты карар бирә:

1. 1939 нчы елда чыгарылган 2 нче номерлы мәҗбүри карарның 2 нче пунктының һәм 37 нче пунктының икенче өлешләрен бетерергә һәм бөтен урамны, шулай ук трамвай юлларын да кардан, боздан һәм чүп-чардан тазартуны йорт идарәләренә, йорт хуҗаларына һәм йорт арендаторларына йөкләргә.

2. 1939 нчы ел, 11 нче гыйнварда чыгарган 2 нче номерлы мәҗбүри карарның 38 нче пунктын түбәндәгечә редакцияләргә:

„Йорт идарәләре, карарның 32 нче пунктында күрсәтелгән сәгатьләрдә, трамвайлар туктау урыннарын аеруча җентекләп кардан тазартырга һәм ул урыннарга ком сибәргә тиешләр“.

38 нче пунктның искәрмәсен бетерергә.

3. Бу мәҗбүри карар игълан ителгән көннән үк үз көченә керә.

Казан Шәһәре Башкарма Комитеты председателе Мурин.

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКА КОНТОРАСЫ—„ТАТКОМПРОЕКТ“
1) район үзәкләрен, эшчеләр поселкыларын, халык тору өчен дача урыннарын, МТС ларны, совхозларны, колхозларны, төзелешләрне планлаштыруның һәм детальне проектларның генераль схемаларын төзү,
2) торак йортлары, больницалар, балалар йортлары, балалар ясленәре, клублар, ашханәләр һәм башка шундыйларны төзү өчен проектлар эшләү һәм аларның схемаларын төзү, типовой проектларны яраклаштыру,
3) яңа торак йортлары, сәүдә, коммуналь һәм башка предприятиеләр төзүне һәм элек салынганнарын реконструкцияләүне проектлаштыру,
4) халык торган урыннарны су белән тәэмин итү һәм канализация үткәрү өчен, шулай ук зданиеләрнең эчендәге—водопровод, канализация, вентиляция, ягу-җылыту системасы һәм электр җиһазлары өчен проектлар төзү буенча
ЭШЛӘР ҮТИ
Казан, Куйбышев урамы, 9. 82—1

КАЗАН ДӘҮЛӘТ МЕДИЦИНА ИНСТИТУТЫ
тире-венера авырулары клиникасында ассистентлык хезмәтен алуга карата
КОНКУРС ИГЪЛАН ИТӘ
Гариза белән бергә, хезмәткә керергә теләүченең афтобиографиясе, кадрлар учеты буенча личный листогы, соңгы хезмәте урыннан белешмә, эше ягыннан һәм политик характеристика, гыйлми дәрәҗәсе турында белешмә, фәнни хезмәтләренең исемлеге (аларның оттисклары) һәм ул хезмәтләр турында булган отзывлар бирелергә тиеш.
Гариза бирү өчен шушы игълан басылып чыкканнан соң ике атна срок билгеләнә. Казан, Чернышевский урамы, 16, Мединститут. 118—1

Питрәч районы Екатериновка авыл советына караган Новая деревня колхозының югалган түгәрәк печатен гамәлдән чыккан дип санарга. 96—1

Казан шәһәре Киров районындагы 204 нче йорт управлениесенең югалган түгәрәк каучук печатен гамәлдән чыккан дип санарга. 65—1

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ
Бүген һәм һәр көн зур программа буенча зур цирк уены.
Москва 4 нче труппасының гастрольләре
ИНТЕРМЕДИЯ
ЧИК ЙОЗАКТА
Кич 8 дә башлана.
АНОНС: РСФСР ның атказанган артисты орденлы
ЗОЛОТО гастрольләре
Атнаның икенче көнендә цирк эшләми.
Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Киров районындагы
Культура сараенда
23 һәм 24 нче гыйнварда
РЕВИЗОР
Талоннар: 23 ндә 44, 45 һәм 24 ндә 46, 47.
Спектакль кич сәгать 8 дә башлана.

КИРӘК:
Таткоопинсоюзга, Казанда һәм районнарда эшләү өчен, БАШ һәм ӨЛКӘН БУХГАЛТЕРЛАР. Хезмәт хакы килешү буенча. Казан, Чернышевский урамы 2. 107—3—2

Киров Райпищеторгына даими эшкә БУХГАЛТЕР-РЕВИЗОР, ДӘГВАЛАР БУЕНЧА ЭШЛӘҮЧЕ БУХГАЛТЕР, БҮЛЕК БУХГАЛТЕРЫ, МАГАЗИНДА ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР һәм БУХГАЛТЕР-ИНСТРУКТОР. Хезмәт хакы килешү буенча. Ягодный бистәсе, Базар мәйданы. Телефон 9—63. 112—2—1

Москва—Казан тимер юлы Казан станциясенең баш буфетына даими эшкә БАШ БУХГАЛТЕР, ГРУППА БУХГАЛТЕРЛАРЫ, ХИСАПЧЫ-КАРТОТЕКАЧЫ, МАШИНИСТКА-ЭШБАШКАРУЧЫ, 1 һәм 2 нче категория ПОВАРЛАР. Казан, Пионер урамы, 40/5. 81—1

Микробиология институтына (Зур Красный урам, 65) ВЕТЕРИНАРИЯ ВРАЧЫ, КОЧЕГАР һәм производство бүлеге өчен ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР. 104—3—2

Галиәсгар Камал исемендәге
Татар Дәүләт Академия театры
21 һәм 22 нче гыйнварда спектакльләр булмый.
23 нче гыйнварда КҮЗЛӘР Талон 101.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ
Бүген, 21 нче гыйнварда
МАСКАРАД
Бүген талон 81.
22 нче гыйнварда спектакль булмый.
23 һәм 24 нче гыйнварда кич
БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА
23 нче гыйнварда
талоннар: көндез 17, кич 82.
Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана.
Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 8 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ЛЕНИН 18 нче ЕЛДА
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8, 10 да.	ЛЕНИН ОКТЯБРЬДӘ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да.	БӨЕК ТАҢ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	МЫЛТЫКЛЫ КЕШЕ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	Көндез МИТЬКА ЛЕЛЮК Кич ЛЕНИН ТУРЫНДА ӨЧ ҖЫР Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яшьтәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	ЦИРК
КУЛЬТУРА САРАЕ 4-30, 7, 9-30 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (Икенче сериясе)

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А —216 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 256.